# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы
Янурыс авыл җирлегенең Каташ-Каран авылы торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

**11 ноябрь 2020 ел** **№1**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2020 елның 11 ноябрендә 10.00 сәгатьтә үткәрелгән гражданнар җыенының «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Янурыс авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булмаган яшәүчедән 2021 елда үзара салым кертүгә, I төркем инвалидлардан тыш, алынган акчаларны түбәндәге эшләрне үтәү буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрүгә юнәлдерү белән килешәсезме?:

1) Каташ Каран торак пунктында зират коймасын ремонтлау (буяулар сатып алу);

2) Каташ Каран торак пунктында урамнар, йорт номерлары, элмә тактлары (килешү буенча эшләр өчен түләү) күрсәтелгән күрсәткечләр әзерләү;

3) яңа елны бәйрәм итү өчен костюмнар сатып алу;

4) Каташ-Каран торак пунктында урамнарны яктырту объектларын карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү (светодиод лампалар сатып алу һәм урнаштыру);

5) Каташ Каран авылында бәйрәмнәр һәм чаралар үткәрү өчен бүләкләр алу.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Җыенда катнашучылар исемлегенә сайлау хокукына ия булган 262 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны - 160 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:
гражданнар җыенында «РИЗА» позициясе өчен 160 катнашучы тавыш бирде;
«КАРШЫ» позициясе өчен __0____ катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карар итте:

1. Сарман муниципаль районының Янурыс авыл җирлегенең Каташ-Карана вылы торак пунктында гражданнар җыенын узган дип танырга, гражданнар җыены нәтиҗәләрен гамәлдә дип танырга.

2. «2021 елда 250 сум күләмендә Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Янурыс авыл җирлеге территориясендә I төркем инвалидлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерү өчен үзара салым кертергә килешәсезме » дигән сорау буенча карар кабул итәргә:

1) Каташ Каран торак пунктында зират коймасын ремонтлау (буяулар сатып алу);

2) Каташ Каран торак пунктында урамнар, йорт номерлары, элмә тактлары (килешү буенча эшләр өчен түләү) күрсәтелгән күрсәткечләр әзерләү;

3) яңа елны бәйрәм итү өчен костюмнар сатып алу;

4) Каташ-Каран торак пунктында урамнарны яктырту объектларын карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү (светодиод лампалар сатып алу һәм урнаштыру);

5) Каташ Каран авылында бәйрәмнәр һәм чаралар үткәрү өчен бүләкләр алу кабул ителгән.

3. Гражданнар җыены нәтиҗәләрен Янурыс авыл җирлегенең мәгълүмати стендларына урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Сарман муниципаль районының рәсми сайтында (http:/ https://sarmanovo.tatarstan.ru/), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 7 көн эчендә бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Янурыс авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Сарман муниципаль районы
Янурыс авыл җирлеге башлыгы,
Халык җыенында рәислек итүче А. Ә.Мөхәммәдиева